ФОМА УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ УКУЧЫЛАРЫНЫҢ АЙЛЫК ГАЗЕТАСЫ

# «КӨЗГЕ»

КӨЗГЕ

НОЯБРЬ,
2018нче ел

№3 (43)

**ҮЗЕҢ НИНДИ, КӨЗГЕҢ ШУНДЫЙ!!!**





Игътибар:

4 ноябрь-Халыклар бердәмлеге көне

10 ноябрь- Яшьләр көне

25 ноябрь- Әниләр көне

28 ноябрь -Халыкара сабырлык көне

## Ура-а-а!!! Каникуллар.

Ноябрь ае каникуллар белән башланып китте.Яңа уку елы әле башланып кына киткән кебек иде, инде көзге каникуллар да килеп җитте, беренче чирек тәгәлләнде.

Мәктәпләр дә дә бер үк вакытта каникул булдыру балалар өчен дә, өлкәннәр өчен дә кулай. Каникул вакытында укучылар өчен мәктәптә төрле чаралар үткәрелде. Укучылар бик теләп катнаштылар. Төрле түгәрәкләр эшләде. Шулай ук мәктәп каршында «Спорт -Экспресс» сәламәтләндерү лагеры эшләде.

Лагерьда 9,11 сыйныф укучылары 15 бала ял итте. Аларга педагог—оештыручы Садртдинова Рузилә Нурислам кызы төрледән төрле уеннар, конкурслар оештырды. Укучылар бик теләп лагерьга йөрделәр.

**Аглетдинова Гөлләр**

## 1 чирек нәтиҗәләре

Зур шатлыклар, якты өмет –хыяллар белән башланып киткән уку елының I чиреге сизелми дә үтеп китте. 2018/2019 нче елда мәктәбебездә 83бала белем һәм тәрбия ала. Уку буенча беренче чирек нәтиҗәләренә күз салсак, иң югары күрсәткеч башлангыч сыйныфлар арасыннан - 2 нче сыйныфларда 60%.

I чирекне 22 укучы “4”ле һәм “5”ле билгеләренә тәмамлады Алар: Валиуллин Нияз, Хайбуллина Фатыйма, Камалова Диләрә,Галлямова Әдилә, Менгазов Дамир, Аглетдинов Адел, Зкирова Диана, Абдрахманов Рифат, Тагиров Илмир, Салахова Әдилә, Тагиров Габдерәхим, Хисматова Зәринә,Аглетдинова Гөлләр, Хайруллин Әдилә, Тагиров Булат, Тагиров Иллар,Закирова Гөлинә,Масгутов Гөлназ, Хисматов Рәсим, Гумерова Ләйсән, Зарипова Зилә, Гумеров Ранис..Сыйфат түбәндәгечә: 2 сыйныф - 60%, 4 сыйныф – 25%, 5 сыйныф – 50, 6 сыйныф – 22%, 7 сыйныф – 50%, 8 – 38%, 9 – 11%. Аларга алдынгы класслардан үрнәк алырга дигән киңәш бирәбез. Мәктәп буенча күрсәткеч 34%.

**Бу санда:**


| | |
|---|---|
| Ура! Каникуллар. | 1 |
| Мәктәп тормышы | 2 |
| Мин һәм минем хокукларым. | 3 |
| Ана бөек исем! | 4 |
| Сак бул! Көзге боз өсте | 5 |
| Ял сәгатьләрендә | 6 7 |
| Котлыйбыз! | 8 |



# Мәктәп тормышы

9 ноябрь көнне Нурлат шәһәрен-дә “Россия укучыларының хәрәкәте” оешмасының туган көне билгеләп үтелде. Безнең мәктәптән дә “Россия укучыларының хәрәкәте” һәм «Яшь инспекторлар хәрәкәте” оешмасыннан укучылар актив катнашып кайттылар.





28 ноябрь көнне 12.00 -15.00 сәг.кә кадәр «Мөстәкыйль төркем балалары” «Барс» отря-ды членнары наркотикларга каршы «Үлем белән кайда сату итәләр, хәбәр ит» акциясе үткәрделәр. Бу акцияне укучылар авылыбыз урамнарында, оешмаларда, кибетләрдә уздырдылар. Укучылар кешеләр белән сөйләштеләр, наркотиклар белән теләсә нинди гамәл – сатып алу, саклау, сату, кулланырга җәлеп итү җинаять саналуын аңлаттылар .

27 ноябрь көнне мәктәбебездә SaMoStоятельные дети проекты «Исән әни– исән бала» дип исемләнгән акция үткәрделәр. Ярату билгесе йөрәк тараттылар һәм һәркешенең беләгенә кызылсары тасма бәйләделәр.





30 ноябрь көнне Якушка урта мәктәбендә «Ел укытучысы-2018» конкурсының куст этабы булып үтте. Анда 4 авыл мәктәпләре арасыннан укыту-чылар катнашты һәм Безнең мәктәптән Садртди-нова Р.Н. җиңүче булды һәм муниципаль этапка үтте. Уңышлар аңа.


# Мин - бала! Баланың

К е ш е һ әм гражданлык хокуклары балага, яшүсмергә дә турыдан - туры кагыла. Бу хакта 1989 елда Бала хокуклары турында конвенцияне кабул иткән. Берләшкән Милләтләр Оешмасы Генераль Ассамблеясында әйтелде. 1990 елда илебез планетада балаларның гомерен һәм хокукларын яклаучы әлеге халыкара документка башкару өчен имза салды һәм граданлык, гаилә һәм хезмәт законнарында бала хокукларын беркетте. Конвенция буенча “18 яше тулганчы һәр кеше заты” бала дип танылa. Димәк, халыкара хокук позициясеннән караганда хәзерге заман яшүсмерләрен бала итеп карарга мөмкин.Ул – кеше һәм үз дәүләтенең яшь гражданины булып тора. Бу-кешенең (өлкән кешенең) төп хокуклары балага да (ләкин төрле күләмдә һәм төрле дәрәҗәдә) кагылырга тиеш дигән сүз. Бала хокуклары турындагы конвенциянең төп фикере: бала – тулы кыйммәтле шәхес. Аның үз хокуклары һәм бурычлары бар. “Начар балалар булмый!” Проблемалы балалар була, хаталанган балалар була. Ләкин олылар балаларга карата мәрхәмәтсез булырга тиеш түгел.

Гайнуллина Алия.

# Мин һәм минем хокукларым

Кеше хокукларын, аеруча бала хокукларын яклау дәүләтнең иң мөһим бурычларының берсе булып тора. 20 ноябрь – Балаларның хокукларын яклау көне. Бу көн 145 илдә билгеләп үтелә. Һәм аның 20 ноябрьгә билгеләнүе очраклы түгел. Нәкъ шушы көндә 1959 елда бала хокуклары декларациясе, ә 1989 елда бала хокуклары турында Конвенция кабул ителә. Бу көнне барлык илләрдә балалар хокукларын яклауны искәрткән




аралар оештырыла. Нәкъ 20 нче ноябрь көнне мәктәбебездә тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы Фахреева Г.Я. уртанчы сыйныф укучылары белән “Минем хокукларым” дигән темага сыйныфтан тыш чара үткәрде. Укучыларга үзләренең хокуклары турында мәгълүмат җиткерелде, аларны кызыксындырган сорауларга җаваплар бирелде. Ә башлангыч сыйныфларда Галлямова Гөлүсә Фоатовна «Мин бала! Минем хокукларым» темасына чара үткәрде.

Масгутова Г.






# Ана – бөек исем



## Иң кадерле әнием



Ноябрьнең соңгы якшәмбесендә без һәркемнең йөрәгенә бик якын бәйрәм – Әниләр көнен билгеләп үтәбез. Бу бәйрәм – балаларыгызның сезгә хөрмәт күрсәтү һәм ятратуларын белдерү көне генә түгел, әниләрнең һәр кеше һәм җәмгыять тормышында бик зур роль уйнавын тану да.Әни – тормышын башыннан алып ахырынача безгә, балаларга багышлаган бердәнбер кеше ул. Безгә ничә яшь булуына карамастан, нәкъ менә әниләр уңышларыбызга иң нык сөенүче, яклаучы, күңелсезлекләргә көенүче, баласының тормыш юлындагы һәр адымы өчен чын күңелдән борчылучы да. Һәр әни үз баласының лаеклы тормышта яшәвен, акыллы, укымышлы, уңышлы, матур, кешеләрнең хөрмәтенә лаек булуын тели.

Бездә булган барлык яхшы, мөһим нәрсәләр – гаилә җылысы, уңайлыклар, хәтта тормышыбыз өчен дә без сезгә – әниләргә бурычлы.

Әниләр бәйрәме уңаеннан мәктәбебездә төрле чаралар узды. Әниләргә багышлап язылган шигырьләр конкурсына нәтиҗәләр ясалды. Җиңүчеләрнең әсәрләре район конкурсына җибәрелде. Радио узелдан мәктәбебездә эшләүче барлык әниләрне бәйрәм белән котлап чыгышлар ясадылар. Авыл клубында әниләребезгә багышланган бик матур җырлы-уенлы кичә булып узды.

Шайдулова Сиринә




**Мәкальләрне дәвам ит**

Өйнең яме әни белән.
Эти – шикәр, әни – бал.
Әни йорты – алтын бишек.
Кояш – якты, әни – яхшы.
Иң йомшак кул – әни кулы.



* Ана яхшылыгын авырсаң белерсең.
* Ана - шәфкать диңгезе.
* Анасыз корт бал җыймас, бал җыйса да мул җыймас.

# Көзге боз өсте: сак булыгыз, хәтәр!

Елгаларда су 10 сантиметр калынлыкта катса гына кеше өчен куркыныч булмый. Елга тамакларында, камышлыкларда боз юкарак була. Әгәр һава температурасы өч көн дәвамында 0 градустан югарырак тора икән, бозның калынлыгы 25 процентка кими. Бозның калынлыгын гади күз белән дә билгеләп була: зәңгәрсу төстәге боз – ныклы, ак төстәгесе юкарак, соры яисә саргылт булса, ышанычсыз.

Әгәр дә боз өстендә бәла-каза чыкса, паникага бирелмәскә, кискен хәрәкәтләр ясамаска кирәк. Әгәр дә, боз ярылып, салкын суга батсагыз, нишләргә?

Бу очракта кулларны җәеп, ничек тә булса, бозга башта бер аякны, аннан соң икенчесен күтәреп, шуышып, менәргә кирәк. Әгәр дә боз сезнең авырлыкка чыдаса, әкрен генә ярга таба үрмәләргә була. Кайсы ярдан килгәнсез, шул якка үрмәләргә кирәк, чөнки анда боз тикшерелгән.

Әгәр дә Сезнең ярдәм таләп ителсә, нишләргә?

Озын таяк, такта, яисә бау табарга. Йә булмаса шарф, каеш һәм киемнәрне бергә бәйләргә була. Бозга ятып, шушы әйберләр белән бәлагә таручы ягына шуыша башлагыз. Суга батучы янына җитәргә бер-ике метр калгач, туктарга һәм таякны, тактаны яисә бауны кирәк кадәр. сузып, бәлагә таручыны куркыныч зонадан чыгарырга тырышыгыз. Зыян күрүчене коткаргач, җылы урын табып, аның юеш киемнәрен салдырырга, тәнен спирт яисә аракы белән ышкырга, кайнар чәй эчерергә кирәк. Әмма беркайчан да суга батучыга эчәргә аракы бирмәгез. Ул аны үлемгә китерергә мөмкин.





## Алар олимпиадада мәктәп данын яклаячак.

Республикабызда да предмет олимпиадалары хәрәкәте бик киң җәелдерелгән. Олимпиадаларның төп максаты һәм бурычлары − укучыларда танып-белү эшчәнлегенә кызыксыну уяту, сәләтле һәм талантлы балаларны ачыклау, алар белән эшләү тәҗрибәсе туплау.

Сәләтле балаларны олимпиадаларга әзерләү укытучыдан системалы эш һәм бик зур тырышлык таләп итә. Шуңа күрә әлеге эшне башлангыч сыйныфлардан ук башлыйбыз. Нәтиҗәгә ирешәсең килә икән, әзерлекне ел дәвамында алып барырга кирәк

Укучыларны олимпиадага әзерләгәндә аларның сүз байлыгын үстерүгә, телдән һәм язмача аралашуга, үз фикерләрен төгәл, ачык белдерә алуларына зур игътибар бирәбез.

Мәктәбебез укытучылары һәм укучылары да ел әйләнәсе олимпиадага әзерлек белән шөгыльләнә. Сәләтле укучыларны сайлап алып, аларны үз фәннәре белән кызыксындыру өстендә эшлиләр. Олимпиаданың мәктәп туры үткәрелгәннән соң һәр җиңүче укучы район олимпиадасында катнашу һәм җиңүне максат итеп куя. Даими һәм системалы әзерләнү үзенең нәтиҗәләрен бирә. Мәктәп буенча үткәрелгән олимпиадада үзләренең көчләрен сынаган укучылар түбәндәгеләр: Гумерова Ләйсән, Хисматов Рәсим, Хисматова Зәринә, Зарипова Зилә, Менгазов Дамир, Галлямова Әдилә, Аглетдинов Адель, Гайнуллина Алия, Гайсина Гөлшат, Тагирова Гайшә, Аглиуллин Аяз, Гумеров Ранис.Бу укучыларга район турында җиңүче булып республика этабында катнашырлар дип өметләнеп калабыз.

Декабрь аенда район турында җиңүче укучыларыбызның олимпиадалар нәтиҗәсе белән газетабызның киләсе санында таныштырырбыз.




Ноябрь аенда туучы кадерле

укытучыларыбыз һәм

техник хезмәткәрләребез:

Гомәрова Флүсә Фоат кызы,

Садретдинова Гөлназ Ринат кызы,

Сезне гомер бәйрәмегез-туган көнегез белән чын күңелебездән тәбрик итәбез.Шундый авыр эшне жиңел итеп алып барып, көчле рухлы, ярдәмчел, түземле булып, кайгы-хәсрәт күрмичә, тигезлектә, балаларыгызның игелеген тоеп, баш-каларга үрнәк булып яшәвегезне телибез.

Зур бәхетләр юлдаш булсын сиңа,
Көннәреңне шатлык бизәсен.
Сәламәтлек – ярты бәхет, диләр,
Шушы бәхет читләп үтмәсен

Хөрмәтле

Зәкирә Закирҗан кызы !

Сезне алтын юбилеегыз белән чын күңелдән котлыйбыз. Сезгә нык сәламәтлек, күңел тынычлыгы, гаилә шатлыгы, кайгы-хәсрәтсез көннәр, ак бәхетләр, балаларыгызның һәм оныкларыгызның күңел жылысын тоеп, игелекләрен күреп, бәхетле озын гомер кичерүегезне телибез. Киләчәгегез жыр кебек матур, кояш кебек якты булсын. Туачак таңнарыгыз һәрвакыт нурлы, күк йөзегез һәрвакыт аяз булсын. Гел шулай ел-маеп, кешеләрне сөендереп яшәгез.



Ноябрь аенда туучы

кадерле укучыларыбыз:


Григорьев Антон, Шайдуллова Сиринә, Гайнуллина Алия, Гайнуллин Эдурад, Садртдинова Рузилә, Таһирова Гайшә, !

Сезнең барыгызны да чын күңелебездән туган көнегез белән тәбрик итәбез. Сезгә укуыгызда зур уңышлар , нык сәламәтлек телибез.

Озын булсын гомерегез,
Тыныч булсын күңелегез.
Бәхет чишмәләрегез мул аксын,
Зур шатлыклар белән таң атсын!



# Кроссвордны чиш




1. Вак кынадыр үзләре, ялтырыйдыр күзләре.
2. Кулы юк, балчык ташый, балтасы юк, өй ясый.
3. Су анасының тарагы нинди материалдан?
4. Бәләкәй генә ак келәт, эче тулы сары май.
5. Үзе сөяксез, сөйләгән сүзе хисапсыз.
6. Ул булса, көн була, ул булмаса, кем була?
7. Эче кызыл шикәрле, тышы яшел бәрхетле.
8. Башы да тишек, төбе дә тишек, уртасында ут, читендә су.
9. Керт-керт тауга менә, керт-керт таудан төшә; и аяулы, аяулы, койрык очы бу яулы.
10. Бәләкәй генә олан, биленә каеш буган.
11. Г.Тукай шигырендә кәҗә белән дус малай?
12. Ашка салсаң - тәм кертә, Борынга салсаң - төчкертә



# Ял сәгатьләрендә

## Биш исем.

Буш шакмакларга берәр хәреф куеп, сулдан уңга укыгач, сүз килеп чыгарлык итеп, 5 исем языгыз.

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| а | | | | а |
| | а | | а | |
| | | а | | |
| | а | | а | |
| а | | | | а |



## 6 исем языгыз.

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| а | | | | | |
| | а | | | | |
| | | а | | | |
| | | | а | | |
| | | | | а | |
| | | | | | а |



Чабышмак табышмаклар.

1.Булма са да ул аксак,
Бара суга аксаклап.

2.Һәрвакыт алдан чабар

“ К Ө З Г Е ”

**Директор:** Сафиуллин Хәлим Салихович

***“Фома урта гомуми белем мәктәбе”***

тарафыннан гамәлгә куелды.

(423012 Нурлат районы, Фома авылы,

Газетага нигез салынды: сентябрь, 2011

Газета уку вакытларында айга бер тапкыр чыга.

Тиражы *чикләнмәгән.*

**Баш мөхәррир**: Садртдинова Рузилә Нурислам кызы

**Урынбасары: Гумерова Ләйсән**

**Дизайнер**: Хисматов Рәсим

**Корректор**: Сафиуллина Резидә Дамировна

**Редколлегия:** Зарипова Зилә, Кәбирова Дилбәр, Хисматова Зәринә